СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,42319

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2019 елның «13» ноябреннән № 54-338

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-248 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә өстәмәләр кертү хакында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"гы Федераль законга шәһәр, авыл җирлеге, муниципаль район, шәһәр округы, шәһәр эче бүленеше булган шәһәр округы, шәһәр эче районы җирле үзидарә органнарының кулланучылар хокукларын яклау буенча чараларны тормышка ашыру хокукы өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 29 июлендәге 244-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү, шулай ук торак- төзелеш кооперативлары эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында " 2019 елның 16 октябрендәге 79-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына таянып, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-248 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә түбәндәге өстәмәләр кертергә:

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты вәкаләтләре» нең 4 бүлегендәге 4.1 пунктының 4 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле текст өстәргә:

«-күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контроле буенча үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк банкы белән килештереп, билгеләнгән тәртиптә, төзүчеләргә карата вәкаләтле банктан мәгълүмат соратуларын гамәлгә ашыра;

- күпфатирлы йортның һәм (яки) башка күчемсез милек объектының (төзелеш проектының) әзерлек дәрәҗәсе һәм өлешләп төзүдә катнашу шартнамәләрен Федераль законның 15.4 статьясында каралган счетлардан файдаланмыйча төзү мөмкинлеге турында бәяләмәләр бирә (алга таба- контрольлек итүче органның критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәсе), торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында төзүченең критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмә бирү турында гаризасын урнаштыру, тиешле карар кабул ителгән көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча

контрольлек итүче орган бәяләмәсе критерийларга туры килү яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында тикшерү органы бәяләмәсе бирү турында гариза урнаштыру.»;

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты вәкаләтләре» 4 бүлегендәге 4.1 пунктының 7 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле текст белән тулыландырырга:

«- “Кулланучылар хокукларын яклау турында»1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыра”.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының "Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башлыгы

В.М.Козлов